РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

КАРАР

14 ноябрь 2023 ел №10

«Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Түбән- Шәмәрдән авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2023 елның 28 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок- Шәмәрдән авылы, Совет урамы, 35 нче а йорт адресы буенча урнашкан Починок- Шәмәрдән мәчет бинасында үткәрергә.

2.2023 елның 30 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар Починок- Шәмәрдән авылы, Совет урамы, 35 нче а йорт адресы буенча урнашкан Починок- Шәмәрдән мәчет бинасында үткәрергә.

3.Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: :«1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе

Коралллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылы территориясендә
яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:
- Починок- Шәмәрдән авылында кышын-җәен юлларны карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Починок- Шәмәрдән авылының Совет урамнары буенча юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү,техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;
- янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылы чишмәсен һәм территорясен төзекләндерү, ремонтлау (материаллар алу), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- су белән тәэмин итү челтәрләре өчен проект-смета документларын эшләү, су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау, су насосын алу һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылында зиратларны карап тоту, материал сатып алу һәм койма урнаштыру һәм килешү буенча түләү;
- Починок-Шәмәрдән авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү һәм килешү буенча түләү;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү (килешү буенча түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Җыенны оештыручы итеп Ядегәр авылы башкарма комитетын билгеләргә.

6.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин